БАТЫР ЙӨРӘКЛӘР

Казанда заман геройларын зурладылар

> 2

НӘСЕЛ АГАЧЫ

Коры Көрнәледә Шиһабетдиновлар гаиләсен авылның бизәге дип йөртәләр

> 3

БУЛӘК ТАРАТКАНДА

«Татар җыры» фестиваленең 23 нчесе узды

> 4

ХУШ, КУРАМША!

Татарның бөек баянчысын соңгы юлга озаттылар

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 188 (28961) | Сишәмбе | 20 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

САТАР ТҮГЕЛ, АЛЫР ЧАК

РОССИЯДӘ ТАШЛАМАЛЫ ИПОТЕКА ПРОГРАММАСЫ 1,5 ЕЛГА ОЗАЙТЫЛДЫ

Ташламалы ипотека 2024 елның 1 июленә кадәр озайтыла! Узган атна шундый яңалык белән тәмамланды. Стратегик үсеш һәм илкүләм проектлар советы утырышында Россия Президенты Владимир Путин әлеге программаның тагын 1,5 елга озайтылуын, ставкасының 1 процентка артуын хәбәр итте.

Шул рәвешле киләсе елдан ташламалы ипотеканы 7 урынына 8 процент белән рәсмиләштереп булачак. Бу яңалык торак базарына нинди үзгәрешләр алып киләчәк? «ВТ» хәбәрчесе шуны ачыкларга тырышты.

Бераз сабыр итәсе

Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов ташламалы ипотека программасының 1,5 елга озайтылуы торак базарын әллә ни җанландырмас дип фаразлый. Ташламалы ипотека ставкасының 1 процентка артуы хәлне тагын да катлауландырачак дигән фикердә ул.

– Бүген торак базарында болай да тискәре күренешләр өстенлек итә. Хөкүмәт ташламалы ипотека, гаилә ипотекасы, авыл ипотекасы кебек программалар тәкъдим итсә дә, ипотекага фатир алучылар бик аз. Билгеле булганча, бүген банклар үзләре дә 0,1 процентлык еллык ипотека тәкъдим итә. Әмма бу да торак базарын җанландырып җибәрә алмады. Ник дигәндә, алар бу аерманы барыбер бәягә өстиләр, – ди белгеч.

Илгизәр Гайнетдинов фикеренчә, ипотекага фатир алган кеше кредитын вакытында түләп бара алсын өчен, торак бәясе ким дигәндә 20 процентка төшәргә тиеш. Бүген аларның ни дәрәҗәдә югары икәнен күреп торабыз. Дөрес, ел башы белән чагыштырганда Казанда фатир бәяләре бераз төшкән әле. Чагыштыру өчен: апрель аенда Казанда фатирларның бер квадрат метр бәясе уртача 145 мең сум булса, декабрьгә ул 135–137 меңгә калган. Әмма гади халык өчен монысы да – коточкыч бәя.

– Бүген фатирлар чамадан тыш кыйммәт һәм бу икътисадый яктан берничек нигезләнмәгән, ясалма рәвештә арттырылган бәяләр. Торак базары җанлансын, дисә, хөкүмәт, төзүчеләр үзләре дә торак базарының квадрат метр бәясен киметү ягын да кайгыртырга тиеш, – дип саный Илгизәр әфәнде.

Белгеч фикеренчә, ташламалы ипотеканың процент ставкасы күтәрелү яңа төзелүче йортлардагы фатирларга ихтыяҗның төшүенә китерәчәк. Сорау кимегәч, фатирларның базар бәясе дә төшәргә мөмкин. Шуңа күрә киләсе елда фатир бәяләре 10 процентка кимергә мөмкин, дип фаразлый белгеч. Шуңа күрә якын арада фатир сатып алырга җыенган кешеләргә дә бераз сабыр итәргә киңәш итә ул.

– Якын арада фатир бәяләре төшәр ул. Ник дигәндә, ташламалы ипотеканың 1 процентка артуы аркасында, беренчел һәм икенчел торак базарында үзара көндәшлек башланырга мөмкин. Шуңа күрә фатир алырга теләүчеләргә бераз сабыр итәргә кирәк, – ди белгеч.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Искесенә дә кирәк

Ташламалы ипотека программасының озайтылуы турында игълан иткәндә, Владимир Путин әлеге программаның киләчәктә акрынлап бетерелачәгенә дә ишарә ясады. «Алдан сөйләшкәнчә, ташламалы ипотека программасы бетереләчәк. Әмма без моны акрынлап эшләячәкбез», – диде Президент. Ташламалы ипотека программасының 7дән 8 процентлыга әйләнүен дә шуның бер алымы дип аңларга кирәктер, бәлки.

Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хәсәенов фикеренчә, ташламалы ипотека программасына ясин чыккач, торак базары әллә ни зур югалту кичермәячәк. Ник дигәндә, халыкның бүген ташламалы ипотека алырга да мөмкинлеге юк.

– Ташламалы ипотека программасы яңынча ике ел элек гамәлгә керде. Халыкның фатир сатып алырга, торак шартларын яхшыртырга мөмкинлекләре булсын өчен эшләнде ул. Кызганыч, шушы соңгы ике ел эчендә, яңа йортларда сатылган фатирлар саны арту белән халыкның аны сатып алу мөмкинлеге артып кына калмады, фатир бәяләре дә бик нык үсте. Барлык зур шәһәрләрдә яңа төзелүче йортлардагы фатир бәяләре ике тапкыр диярлек артты. Мисал өчен, ике ел элек Казанда бер бүлмәле фатирны уртача 3,5 миллион сумга алып булган булса, хәзер аларның хакы 6 миллион сумнан артты. Шуңа күрә ташламалы ипотеканың тагын 1,5 елга озайтылуы фатирларга сорауны әллә ни арттырып дип уйламыйм, – ди белгеч.

> Киләсе ел торак базарына тагын бер үзгәреш алып киләчәк. Россиядә гаилә ипотекасын рәсмиләштерү өчен шартлар яхшыра. Киләсе елдан аны 18 яше тулмаган ике баласы булган һәр гаилә рәсмиләштерә алачак. Балаларның кайсы елдан соң туы мөһим түгел. Билгеле булганча, ул 2018 елдан соң баласы туган гаиләләр өчен генә гамәлдә иде.

Ахыры 3 нче биттә >

Кимрәк ярамый

Россия Президенты Владимир Путин киләсе елга хезмәткә түләүнең минималь күләмен (МРОТ) 16242 сум күләмендә билгеләү турында указга кул куйды. Тиешле документ хокукый мәгълүматлар рәсми порталына урнаштырылган. Аның күләме быелгы белән чагыштырганда 6,3 процентка арта. Әлегә МРОТ 15279 сум тәшкил итә.

Моңа кадәр Президент 2023 елда Россиядә яшәү минимумы күләменең җан башына – 14375 сум, эшләүчеләр өчен – 15669 сум, пенсионерлар өчен – 12363 сум, балалар өчен 13944 сум күләмендә билгеләнүе турында указны имзалаган иде.

Исеме билгеле

Россия балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең исеме «Беренчеләр хәрәкәте» («Движение первых») булачак.

«РИА Новости» хәбәренә караганда, хәрәкәттә катнашучылар беренче съездда «Движение первых» дигән исемне сайлаган булган. Әмма соңрак Яшьләр министрлыгы съездда катнашучылардан яңа тәкъдимнәр көрү турында хәбәр иткән. Тавыш бирүгә «Пионерлар», «Беренчеләр хәрәкәте», «Гагарин исемендәге хәрәкәт», «Яңа буын», «Яшьлек» атамалары чыгарылган.

Тавыш бирү йомгаклары буенча «Беренчеләр хәрәкәте» исеме иң күп балл (760) җыйган. Шулай итеп, хәзер яңа оешма «Беренчеләр хәрәкәте» Россия балалар һәм яшьләр хәрәкәте» дип атала.

Ялган булганга күрә

Россия Генераль прокуратурасы Украинадагы махсус хәрби операция турында 125 мең ялган хәбәрне юкка чыгаруга ирешкән. «РИА Новости» язганча, быел 11 ай эчендә прокурорлар ялган мәгълүматларны интернеттан алу турында Роскомнадзорга 1630 таләп юллаган. Экстремистлык һәм террорчылык оешмалары материалларына, рәхсәтсез массакүләм акцияләрдә катнашуга өндәүләрдән торган хәбәрләргә, террорчылык актлары турында фейкларга кагылышлы мәгълүматлар бу.

Нәтиҗәдә Роскомнадзор интернет киңлекләрендәге 189 меңнән артыграк язманы юк иткән. Шуның 125 меңе – махсус операция турында ялган хәбәрләр.

Сүз уңаеннан, алдагы 3 елда прокурорлар Роскомнадзорга интернеттагы мәгълүматларны ябу турында 1012 таләп җибәргән булган.

Кызыл китап калынaя

Татарстанның Кызыл китабына бөҗәкләр һәм гөмбәләрнең яңа төрләре кертеләчәк. Биоресурслар буенча дәүләт комитеты матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, аерым алганда, уртан-лала безелдәвеге (жужелица лесостепная), тутык безелдәвек (жужелица ржавая) сакланучы төрләр исемлегенә кертелә. Алар III – «сирәк төр» категориясендә урын алачак.

Гөмбәгә килгәндә, бөдрә грифола, зонтиксыман полипорус, бөдрә спарассис кебек төрләре Кызыл китапта урын алачак. Галимнәр шулай ук сазлык майлы гөмбәсен (масленок болотный), сөтләгән, түгәрәк споралы җәйле гөмбәне (строчевик круглоспоровый) сирәк төрләр исемлегенә кертергә кирәклеген әйтә.

Кунакчыл Кремль

Быел 11 ай эчендә Казан Кремлендә илнең төрле почмакларыннан 3,5 миллион турист булып киткән. Башкаланың туризмны үстерү комитеты башлыгы Дарья Санникова әйтүенчә, узган елның шушы ук чорындагы (2,8 миллион кеше) белән чагыштырганда, 25 процентка зуррак күрсәткеч бу.

2022 елда Татарстан башкаласын биграк тә Санкт-Петербург, Екатеринбург, Ярославль, Владимир, Чиләбе, Пермьнән килгән сәяхәтчеләр үз иткән.

kzn.ru

Һава торышы

Декабрь яңгырлары

Кышын коеп яңгыр ява, юллар тулысы белән зур бер шугалакны хәтерләтә. Көчле җил һәм ябышкак кар аркасында ут сүнгән авыллар да бар. Белгечләр фаразына караганда, алдагы көннәрдә дә һава торышы көйсез булачак.

КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы мөдире, профессор Юрий Переведенцев әйтүенчә, кышын мондый яңгырлар һава температурасының югары торуы аркасында ява.

– Бүген һаваның уртача температурасы –9, ә 23 декабрьдә –10 булырга тиеш. Без аны «Николай суыклары» дип йөртәбез. Ә чынлыкта ул бит юк. Бу атнаның беренче яртысында Россия Гидрометеоүзәге фаразлары буенча, –8... –9 градус салкын булачак. Ләкин ул нибары икеөч көн генә дәвам итәчәк. Пәнҗешәмбедән кабаттан җылыта башлаячак. Ялларда кабат яңгырлар явачак. Шул рәвешле Көнбатыштан килгән циклон җылы һәм явым-төшем алып киләчәк, – диде ул.

Юрий Переведенцев әйтүенчә, декабрьдә явым-төшем үз нормасын үтәгән инде. Унтугыз көн эчендә җиргә 58 мм явым-төшем яткан. Ялларда гына да 22 мм яңгыр яуган.

– Бу атнада да җомгадан алып якшәмбегә кадәр шундый ук һава торышы көтелә. Яңгыр, юеш кар явачак, юлларда бозлавык сакланачак. Быелгы декабрьдә һава торышы бик тотрыксыз, чөнки җылы циклоннар килә, – диде синоптик.

Синоптиклар, декабрь җылы һәм явым-төшемсез булачак, дип фаразлаган иде. Ләкин соңгысы буенча кышның беренче ае үз нормасын тутырып кына калмыйча, арттырып ук үтәде. Декабрьнең климатик нормасы –8,5... –9 градус булырга тиеш, ди синоптиклар. Ләкин күреп торабыз: быел җылы көннәр күбрәк.

– Кышын коеп яуган яңгыр – аномаль күренеш, – ди Юрий Переведенцев. – Быел һава торышының уртача төзелеклек температурасы югары. Шул рәвешле без декабрь буена шугалакка каршы көрәшергә мәҗбүр. Кызганыч, алдагы көннәрдә дә бу шулай булачак. Һава басымы да бик нык уйный, шуңа күрә сәламәтлеккә дә тискәре йогынтысы булырга мөмкин.

Бу көннәрдә уҗым культураларына да сыналырга туры килә. Чүпрәле районында яшәүче агроном Илдар Усманов әйтүенчә, мондый боз катламнары көзге культуралар өчен бер яктан яхшы булса, икенче яктан куркыныч тудыра.

– Ноябрь ахырында яуган бозлы яңгыр районны утсыз калдырган иде. Бик куркыныч, авыр вазгыять булды, – диде ул. – Бу елларда да көн буе яңгыр яуды. Уҗымнарга килгәндә, әгәр тишелеп чыккан культуралар өстенә җиңел, «коры» кар яткан икән, яңгыр явып, ул аны дымландыра гына. Бу яхшыга. Тик кайбер кырларда кар ятмаган була. Менә андыйлар өчен яңгырлар, боз катламнары бик куркыныч. Мондый вакытта үсемлекләр тончыгып әрәм булырга мөмкин. Мондый хәл булмасын өчен, без ноябрь ахырындагы галәмәтләрдән соң трактор белән бозларны ватып йөрдек.

Татарстан Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт автоинспекциясе машина йөртүчеләргә юлларда сак булырга, бик кирәк булмаганда, озын сәфәрләргә чыкмаска киңәш итә. Ярдәм сорап, 8(843)5333888 телефон номерына Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт автоинспекциясенә, яки 8(843)2919191 телефон номерына Татарстанның Транспорт һәм юл хезмәте министрлыгының диспетчерлык хезмәтенә шалтыратырга мөмкин.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Сүзгә-сүз



Ринат ФӘХРЕТДИНОВ, UFC көрәшчесе:

Хатыным татар кызы түгел, ләкин мин аңа алдан ук әйтеп куйдым: балалар, һичшиксез, татар телен белергә тиеш. Рус телен алар болай да өйрәнәчәк, рус мохитендә үсәләр чөнки. Ничек булуына карамастан, кызым татар телен белергә тиеш. Мин аның белән өйдә татарча сөйләшәм. Әлегә ике телне бергә алып бару авыррак, әмма өйдә бары тик татарча гына.

(«Спорт-экспресс» басмасына әңгәмәсеннән)

ЯҢА ЕЛ САЛАТЫ

Росстат мәгълүматларына ышансаң, «Оливье» салатын әзерләү өчен кирәкле азык-төлек бәясе уртача 8,52 процентка арткан. Белгечләр 2021 елның һәм бу елның ноябрь аендагы уртача бәяләрне чагыштырган.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫТАЙ: ИКЪТИСАДЫЙ ТҮНТӘРЕЛЕШТӘН – СУГЫШКА?

Үткән атнада Көнбатышның Үзәк банклары нәкъ без фаразлаган диапазонда төп ставканы күтәрделәр. Европа Үзәк банкы 2,5 процентлы база ставкасы билгеләде, Англия 3,5 процентка кадәр күтәрде, АКШның Федераль резервы 4,5 процентлы төп ставка белән эш итә. Төп ставкаларны күтәрү инфляциягә каршы көрәш чарасы дип исәпләнелә, әмма ул, кредитларны кыйммәтләндереп, бизнесны авыр хәлгә куя. Дөнья икътисады исә авыр кризис этабына кереп бара.

Токиодагы икътисад белгечләре Кытай икътисадына бәйле начар фаразлар игълан итә башлады. Элегрәк алар чиннар эчке тулай продукт күләме ягыннан АКШны 2028 елда узып китәр дип фаразлый иде. Аннан соң датаны 2033 ел дип билгеләделәр. Хәзер исә бөтенләй тискәре фараз ясыйлар, Кытай үзенең үсеш потенциалын тотып бетерде дип уйлыйлар.

Үткән атна ахырында АКШның Үзәк разведка идарәсе директоры Билл Бернс чин җитәкчелегенең армияне 2027 елда Тайвань мәсьәләсен сугыш юлы белән хәл итәргә әзерләргә әмер бирүе турында белдерде. 2027 ел – Кытай компартиясенең чираттагы съезды датасы ул. Си Цзиньпин үткән съездда, илдә кабул ителгән кагыйдәләрне бозып, яңа срокка сайланды, дилбегәне кулдан ычкындырасы килмәде. Киләсе съездда аңа тагын бер тапкыр үз вәкаләтләрен озайтырга кирәк булачак, чөнки хакимияттән үз теләге белән китү стадиясеннән узды. Күк асты илендә исә икътисадый хәл начарайганнан-начарая. Әҗәтләр проблемасы бугаздан тоткан. Алардан котылуның берничә юлы бар барын. Беренчесе – елга берничә дистә процентлы үсешкә ирешү. Бу мөмкин түгел. Икенче юл – Кытай юанен дөньякүләм валютага әверелдерү. Бу очракта Кытай әҗәте барлык илләргә дә таралып юкарачак. Стакандагы суны табага салган кебек булачак.

АКШ, мәсәлән, шулай яши. Доллардан файдаланганда, барлык илләр дә АКШ әҗәтен үз җилкәләрендә күтәрә, американнарга җиңеллек килә. Пекин да шул юлда тырышлык күрсәтә башлады. Россия юань зонасына тартып кертелде диярлек. Си Цзиньпин гарәп илләрен нефть сәүдәсен юаньга күчерергә өнди. Ул шуңа ирешсә, юань долларны финанс тәхетеннән этеп төшерер иде. Әмма АКШ моңа юл куймаска тырышачак. Якын Көнчыгышның «кара алтын» державалары зур тартыш мәйданына әвереләчәк. Төбәк болай да эчтән кайный һәм ялкынланырга омтыла. Американнар менә шул ялкынга ут үрләтергә тырышачак.

Бу теләкләре барып чыкмаса, Пекинга соңгы юлны сайларга туры киләчәк. Кечкенә генә җиңүле сугыш Си Цзиньпинның абруен күтәреп җибәрер иде. Әмма чиннарга андый сугышта АКШ белән маңгайга маңгай бәрелергә туры киләчәк. Сугышта кемнең отасын әйтү кыен. АКШның отставкадагы генералларының берсе, Тайвань өчен сугыш башланса, американнар беренче атнада ук барлык снарядларын да атып бетерәчәк, дигән белдерү ясады ясавын. Японнарда да шул ук хәл ул, алар да, сугышның беренче этабында ук атарга әйбер калмаячак, дип зарлана. Американнар хәзерге вакытта айга 20 мең снаряд җитештерүне, ә 2025 елга бу күрсәткечне 40 меңгә җиткерүне планлаштыралар икән. Чагыштырыгыз: Россия – Украина конфликтында украиннар көнгә 20 мең снаряд ата, диләр. Шулай да таныырга кирәк: АКШ армиясе гаҗәп зур куәткә ия һәм конфликт була калса, җиңүчене алдан билгеләү кыен.

Россиядә

РОССИЯДӘ – АЛТЫН БИЗГӘГЕ

Россиянең финанс кыры шулай ук җиңелчә тетрәну кичерә. Үзәк банк үткән атнада төп ставканы үзгәрешсез калдырды. Белгечләр фаразлавынча, әгәр чималга бәяләр төшмәсә, 2023 елда Россиядә процент ставкалары түбәнәергә ихтимал.

Әмма ил эчендә акчага ышаныч юк. Бездә бит хәзер доллар белән евро да кәнфит кәгазе урынына йөри. Акчага әйләнсеннәр өчен, аларны чит илгә чыгарырга туры килә. Соңгы бер ел эчендә бай россиялеләрнең, акчаларын чит илгә чыгарып, күчемсез милек сатып алу омтылышы ике тапкыр үскән. Моның нәтиҗәсе ил эчендә бик яхшы күренә. Россиядә күчемсез милеккә бәя төшкәндә һәм ул сатылмыйча ятканда, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә, Төркиядә һәм кайбер башка илләрдә рус капиталы күчемсез милекнең бәясен күкләргә чөя. Россия Үзәк банкы валютаның чит илгә качуына борчылмый. Эльвира Нәбиуллина: «Бу уңайдан ниндидер махсус чаралар күрергә кирәк дип санамыйбыз», – диде.

Финанс министрлыгында исә халык кулындагы долларларны алтынга алыштырырга кирәк дип саныйлар. Март аеннан башлап алтын бәясе 2,5 тапкыр арзанайган икән үзе. Шуңа карамастан, алтын сату күләме 7 тапкыр арткан. 30 тонна алтын коелма шәхси кулларга күчкән инде. Алтын коелмаларны алганда, өстәмә кыйммәт салымы түләү бетерелү дә моңа этәргәндер, мөгаен. Финанс министры урынбасары Алексей Моисеев ел ахырына кадәр сатылган коелмалар массасы 40 тоннага җитәргә мөмкин дип фаразлый. Аның фикеренчә, алдагы ун елда кешеләр кулындагы валютаның 20 процентын алтынга әйләндерсәң, бик яхшы булачак. Соңгы айларда алтынга ихтыяҗ 350 процентка үскән. Бу уңайдан хәтта Үзәк банк коммерция банкларыннан алтын сатып алуны туктаткан. Сатылган коелмаларның 60 проценты бер килограмм авырлыкта икән. Ике проценты килограммнан артык. Калган 38 проценты – килограммга кадәр. Хәзер халык 100 граммнан кечерәк коелмалар сорый башлаган. Саннар кайсы катлауларның үз акчасын алтында сакларга омтылуын ачык күрсәтә.

Аналитиклар алтынны байлык саклау өчен бик үк яхшы актив дип санамый, чөнки бәясе кискен төшә. Бары тик ун-унбиш ел буена саклау өчен алганда гына файда китерергә ихтимал дип бәялиләр. Әмма хәзер финанс базарлары бик тотрыксыз, кәгазь валюталарның берсенә дә ышанып булмый. Криптовалюталар турында әйтеп тә торырлык түгел. Вазгыять кискен үзгәреп, алтын өскә чыгарга мөмкин. Дөньяның иң зур инвестицион банкларының берсе булган Goldman Sachs банкы белгечләре, мәсәлән, биткоин урынына алтын сатып алырга киңәш итәләр. Тиз алышынучан финанс факторларына алтын азрак бирешә дип саныйлар.

УТ ТА, СУ ДА КУРКЫТМЫЙ

Катлаулы тормышыбызда батырлыкка урын һәрвакыт түрдән. Россия күләмендә уздырылган «Батырлык йолдызлыгы» фестивале җиңүчеләрен бүләкләгәндә әйтелгән сүзләр бу. Кеше гомерен коткаручылар һәм куркынычсызлык тәэмин итүчеләрне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Россиянең гадәттән тыш хәлләр министры Александр Куренков котлады.

Тантаналы чара МЧС хезмәткәрләре өчен сөенечле вакыйгадан башланды. Александр Куренков һәм Рөстәм Миңнеханов Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстандагы бүлегенә 10 янгын сүндерү машинасы һәм коткару техникасы, янгын сүндерү буенча 14 мобиль постка сертификатлар тапшырды.

tatarstan.ru

Александр Куренков сүзләренчә, илнең батыр егет-кызларын нәкъ менә Казанда котлау очраклы хәл түгел.

– Әлеге фестиваль инде 14 ел рәттән дистәләгән мең кешене берләштерә, төрле хәлләрдә батырлык күрсәткән осталарны җыя. Фестивалебезнең геройлары – гадәттән тыш хәлләр белән эшләүче төрле һөнәр ияләре. Алар, ел дәвамында үз юнәлешләрендә иң яхшысы булып танылу өчен, гаять зур көч түкте. Фестиваль киләчәктә дә җәмгыятькә батырлык, кыюлык, үз эшеңә мәхәббәт һәм тугрылык идеяләрен таратыр, колачларын тагын да киңрәк җәяр, яшь буынны тәрбияләүдә мөһим рольләрнең берсен башкарыр дип ышанам, – диде ул. – Җиңүчеләрне бай тарихлы, заман белән бергә атлый торган Казан шәһәрендә бүләкләвебез очраклы түгел. Татарстан – берничә буын геройларның, талантлы гаскәр башлыкларының туган җире ул.

Мәскәүдән килгән кунакның сүзен Татарстан Президенты дәвам иттерде.

– Әлеге фестиваль чын мәгънәсендә халык бәйрәменә әйләнде, дисәм, һич арттыру булмас. Ел саен Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының елъязмасы батырлык кыйссалары, яңа буын геройларының исемнәре белән байый. Алар – үзләрен кызганмыйча, гомерләренә куркыныч янаганда да башкаларга ярдәмгә ашкынучылар. Бүген без Россиянең иң яхшы МЧС хезмәткәрләрен хөрмәтлибез. Катлаулы тормышыбызда батырлыкка, мәрхәмәткә, үзара ярдәмгә урын һәрвакыт түрдән. Һәркайсыгыз – үз иленең чын патриоты. Хезмәтегез һәм йөрәгегез кушканга, Ватан хакына һәм кешеләр гомере өчен көрәшәсез. Бу хезмәтегез өчен сез зур ихтирамга лаек, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Алда әйтелгән сүзләрне уттан курыкмаучы батырлар үзләре дә куәтләде. МЧСның Алтай крае буенча баш идарәсенең янгын сүндерү бүлеге мастеры – «Батырлык йолдызлыгы» фестивалендә «Иң яхшы янгын сүндерүче» номинациясендә җиңү яулаган Алексей Петров үз һөнәренең нечкәлекләре турында сөйләде.

– Безнең эштәге төп кагыйдәләрнең берсе – үз-үзеңне корбан итү. Без барыбыз да, башкаларны коткарганда, үз гомеребезне куркыныч астына куюыбызны яхшы аңлыйбыз. Янгын сүндерү – күмәк эш. Монда һәркем үзе өчен генә түгел, иптәшенең тормышы өчен дә җаваплы. Билгеле, курыккан чаклар да була. Ләкин тыныч вакытта без тик утырмыйбыз: шөгыльләнәбез, камилләшәбез, янгынга рухи яктан да, физик яктан да әзерләнәбез, – диде ул.

Герой булып тумыйлар

«Безнең заман геройлары» иҗтимагый премиясе лауреатларын бүләкләү тантанасында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин шулай диде. «Бәшир Рәмиев исемендәге IT парк» технопаркында узган очрашуда көндәлек тормышта батырлыклар эшләгән кешеләрне бүләкләделәр.

Кыю һәм тәвәккәл, авыр минутларда башкаларга ярдәмгә килүчеләрне Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

– Яшьләр, өлкәннәр арасында заман геройларын табу, җәмгыятькә күрсәтү һәм аларга тиешле бәя бирү бүген бик мөһим. Үз гомерләрен куркыныч астына куеп, йөрәк кушуы буенча ярдәм итүчеләребез белән чын күңелдән горурланабыз. Россия һәм Татарстан һәрвакыт үз каһарманнары белән данлыклы булды, аларның югары эшләре белән горурланды. Минемчә, бу иҗтимагый премия лауреатлары елдан-ел күбрәк булыр, чөнки батырлык өчен вакыт һәм урын һәрвакыт бар, – диде ул.

«Бердәм Россия» партиясе һәм «Яшь Гвардия» оештырган «Безнең заман геройлары» премиясе кысасында «Кечкенә геройлар» форумы җиңүчеләрен дә бүләкләделәр. «Һәр буынның – үз геройлары. Безнең яшьләр бик яхшы, ата-бабаларына лаеклы алмаш буын үсә. Без моңа бүген тагын бер кат инандык», – диде Дәүләт Советы Рәисе.

Премия лауреатларының иң кечкенәсенә – 11, иң өлкәненә – 71 яшь. Алар кеше гомерен коткара, җинаятьчелеккә каршы көрәшә, дәвалану өчен акча җыя, балаларны тәрбиягә ала, волонтерлык эшендә катнаша. Тантанада Тимур хәзрәт Ибраһимов белән православ рухание иерей Виталий Беляевны да бүләкләделәр. Күптән түгел махсус хәрби операция зонасындагы сугышчыларга гуманитар ярдәм илтеп кайткан Тимур хәзрәт үзен геройга санамый. «Мин – офицер, 6 ел элек Уфада хәрби имам курсларын тәмамладым. Яшем буенча мине «Алга» һәм «Тимер» отрядларына алмыйлар. Шуңа күрә хәрби хәрәкәтләр зонасына бару, алгы рәттә булу – минем бурычым», – диде ул.

Ләйсән САФИНА

ТАТАРСТАН КҮПЕРЕ

Россия белән Якын Көнчыгыш арасына күпер Татарстан аша салына. «Татарстан ике арадагы мөнәсәбәтләрне ныгытырга ярдәм итә», – диде Рөстәм Миңнеханов Катарга эш сәфәре барышында.

Татарстан Президенты, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме Рәисе Рөстәм Миңнеханов бер көнлек эш сәфәре белән Катарга барып кайтты. Анда ул «Дарб ас-Саи» мәдәният фестивалендә катнашты. Бу көнне Катарда ил көнен билгеләп уздылар. Татарстан Президентын әлеге чарага шәрәфле кунак буларак чакырганнар.

Рөстәм Миңнеханов мәдәният министры шәех Әбдеррахман Әл Тани белән очрашты. Алар «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме эшчәнлеге кысасында хезмәттәшлек турында сөйләштеләр. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, төрле халыкларның мәдәният-цивилизация үзенчәлекләрен саклап калу – эш төркеменең төп юнәлешләренең берсе. Ислам хезмәттәшлеге оешмасының даими әгъзасы буларак, Катар Россиянең Якын Көнчыгыштагы мөһим һәм ышанычлы партнеры булып санала.

Эш сәфәре кысасында Рөстәм Миңнеханов Катар дәүләте Әмире шәех Тамим бән Хамад Әл Тани белән дә очрашты. Президент Әмирне һәм барлык Катар халкын илкүләм бәйрәм белән котлады. «Катар белән Россия арасындагы мөнәсәбәтләр эзлекле рәвештә алга таба үсә. Татарстан ике арадагы мөнәсәбәтләрне ныгытуда ярдәм итәргә тырыша», – диде Рөстәм Миңнеханов. Республика башлыгы әйтүенчә, Россия Ислам дөньясы, Ислам хезмәттәшлеге оешмасы белән үзара элемтәләргә зур әһәмият бирә. Яклар «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме эшчәнлеге кысасында хезмәттәшлек мәсьәләләре турында фикер алышты.

Фикер

Марат ГАЛИЕВ, Татарстан Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты әгъзасы:

– Соңгы бер елда дөнья күләмендә вазгыять бик нык үзгәрде. Санкцияләр аркасында, Россиядән күп кенә чит ил компанияләре китте. Бу, шул исәптән, Татарстанга да кагылды. Шуңа күрә Татарстан Президентына, алмаш булырлык хезмәттәшләр эзләп, чит илләргә бик күп сәфәр кылырга туры килә. Чөнки санкцияләр кертелү аркасында, икътисад кичергән югалтуларны тулыландыру һәм икътисадны үстерү бурычы тора. Бу – җиңел генә эш түгел. Өстәвенә Европа илләре белән ике арада логистикага да зур зыян килде. Шуңа күрә бүген без кыен хәлдән чыгу юлларын эзләргә мәҗбүр. Бу нисбәттән, Көнчыгыш һәм гарәп илләре белән элемтәләрне җайларга тырышалар. Гомумән алганда, әлеге юнәлештә уңышлар бар. Татарстан Президентының эш сәфәрләренең күп булуы үзгәреп торучы вазгыятькә бәйле. «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме Рәисе буларак, Рөстәм Миңнехановның чит илләрдә Россиянең рәсми вәкиле буларак чыгыш ясавын да аерым искәртеп узасым килә. Мич башында утырып кына бернәрсәгә дә ирешеп булмый. Мондый сәфәрләргә гомуми күзлектән карарга кирәк. Рөстәм Миңнехановның чит илгә эш сәфәрләренең уңай нәтиҗәсе – күз алдында.

Ел инженерлары билгеле

Татарстан Сәүдә-сәнәгать палатасында «Ел инженеры» III республика бәйгесенең бүләкләү тантанасы узды. Җиңүчеләрне һәм лауреатларны республика җитәкчелеге исеменнән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

Парламент башлыгы әйтүенчә, быел бәйге көндәшлекнең көчәюе, санкцияләр басымы шартларында узса да, асылда барлык тармакларны колачлауга ирешкән. Анда республиканың төп вузлары һәм предприятиеләреннән талантлы яшь, шулай ук тәҗрибәле инженерлар катнашкан.

– Казанышларыгыз төп предприятиеләр һәм инженерлар әзерләүче вузлар белгечләре тарафыннан югары бәяләнде. Оешмаларыгызның җитештерү мөмкинлекләрен үстерүгә, көндәшлеккә сәләтен көчәйтүгә лаеклы өлеш кертәсегезгә ышанам, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Республика оешмалары һәм предприятиеләренең халыкта ихтыяҗ зур булган продукциясе артында инженерлар тора. Әлеге һөнәр нефть чыгару, нефть эшкәртү, нефть химиясе һәм машина төзелеше өлкәләрендә зур казанышларга ирешергә ярдәм итә.

«Ел инженеры» республика бәйгесе Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов боерыгы белән гамәлгә куелган. Быел бәйге 3 категория буенча үткәрелгән: инженерлык белгечлекләре буенча белем алучы студентлар өчен – «Булачак инженерлар»; предприятиеләрдә эшләүче 35 яшькә кадәрге инженерлар өчен – «Яшьлек, уңыш, перспектива»; 35 яшьтән өлкәнрәк инженерлар өчен – «Тәҗрибә, казанышлар, компетентлык».

ҮЗЕБЕЗНЕКЕ БУЛАЧАК

Барысын да үзебезгә җитештерергә туры киләчәк! «Идея» технопаркында республиканың фәнни-технологик үсеше турында сөйләштеләр. Ни эшләргә җыеналар?

Татарстан Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советының фәнни-технологик үсеш буенча эшче төркемнең күчмә утырышында Татарстан Президенты Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Президент ярдәмчесе, эшче төркем рәисе урынбасары Альберт Гыйльметдинов, цифрлы үсешкә булышу ассоциациясе рәисе, эшче төркем рәисе урынбасары Рифкать Миңнеханов һәм башкалар катнашты. Әсгать Сәфәров күчмә утырышларның мондый формасын уңай бәяләде. «Биредә инновацияле инфраструктура, предприятиеләр эшчәнлеге белән турыдан-туры танышу мөмкинлеге бар. Чираттагы утырышларны югары уку йортлары һәм предприятиеләрдә планлаштырырга кирәк», – диде ул.

Чарада катнашучылар иң элек технопарктагы мөмкинлекләр белән танышты. Мондагы төп резидент – «Эйдос-Медицина» компаниясенең реверсив инженерия лабораторияләрендәниләр эшләнгәнне күрсәттеләр. Компаниянең генераль директоры Ленар Вәлиев әйтүенчә, алар медицина, газ-нефть өлкәсе, робот техникасы, сәнәгатьтә автоматлаштыру юнәлешендә эшли. Медицинага килгәндә, төрле уникаль диагностик системалар, ПЦР-тестлар уйлап табалар. Боларны хәзер профессиональ медицина оешмаларында кулланасалар, тора-бара яңалыклар өйләргә дә килеп җитәр, дип өметләнәләр.

– Эшебез кимемәде. Үсеш бар, әмма ул планлаштырылганнан бераз азрак. Җитештерү күләмен саклыйбыз. Әйтик, миллионлаган тест, меңләгән робот ясыйбыз. Аларны төрле илләргә җибәрәбез, – диде Ленар Вәлиев.

Белгечләр фикеренчә, чит илләр керткән чикләүләр, киресенчә, үсешне арттырган. Моны Рифкать Миңнеханов та дәлилләде.

– «Идея» технопаркы кебек урыннар саны артырга тиеш. Уку йортлары, бизнес, заводлар арасында элемтә булу мөһим. Бүген бу эштә әкренләп уку йортлары да катнаша. Санкция басымы эшләгән кешегә сизелми. Бүген мондагы хуҗалар да шул хакта әйтте. Алар матди һәм икътисадый яктан чыгу юлын һәрвакыт таба белә. Эшләнмәләрен чит илләргә җибәрүдә проблема юк. Чикләүләр эшне көчәйтте, үзебезнең җиһазларга күчүнең нәтиҗәсе бар. Бөтенләй булмаса да, күп яктан көчәябез, – диде Рифкать Миңнеханов.

Альберт Гыйльметдинов Россия Президенты карары белән «Россиядә фән һәм технология унъеллыгы» игълан ителүен искә төшерде. Татарстан бу вакыйгаларның үзәгендә булачак.

– Илебездә технологик суверенитетка ирешү максаты куела. Бу – бик авыр эш. Моңа кадәр машина, җиһазлар, технологияләрне чит илләрдән сатып ала идек. Хәзер геосәясәткә бәйле вазгыять икенче. Шуңа күрә үзебезгә уйлап табарга, җитештерергә кирәк. Советлар Союзында без бу юлны бер мәртәбә үттек инде. Бөтенләй егылган идек бит. Ләкин иң алдынгы фән, технологияләр шул заманда әкренләп кайтарылды, – диде Альберт Гыйльметдинов. – Республиканың фән һәм технология базасы зур. Бездә уку йортлары, заманча предприятиеләр күп. Фән һәм предприятиеләргә бергәләп эшләргә кирәк.

Сәрия МИФТАХОВА

Тынычлык һәм иминлек өчен

20 декабрь – Россия иминлек органнары хезмәткәрләре көне. Татарстанның иминлек органнары хезмәткәрләрен һәм ветераннарын һөнәри бәйрәмнәре белән Премьер-министр Алексей Песошин котлады.

«Иминлек органнары һәрвакыт дәүләт идарәсе системасының мөһим өлеше булып тора, – диелә котлауда. – Ил мәнфәгатьләрен һәм иминлеген саклау, Россиянең конституцион төзелеше, суверенитеты һәм территориаль бөтенлегенең какшамаслыгын, җәмгыятьтә тотрыклылыкны тәэмин итү сезнең өчен изге һәм мактаулы бурыч булып тора.

Үткәндәге чор каһарманнары үрнәкләрендә тәрбияләнгән иминлек органнары хезмәткәрләренең, антка һәм хезмәт бурычына тугрылыклы калып, алдагы буыннар булдырган традицияләрне киләчәктә дә дәвам иттерәчәкләренә ышанам.

Иминлек органнары ветераннарына аерым җылы рәхмәт сүзләрен җиткерәсем килә. Сез Ватанга хезмәт итү үрнәгендә яшь хезмәткәрләрне һөнәри яктан үстерүдә үзегездән саллы өлеш кертәсез, аларга бай тәҗрибәгезне тапшырасыз, һәлак булганнарның гаиләләренә төрле яклап ярдәм итәсез.

Фидакарь хезмәтегез өчен эчкерсез рәхмәт! Киләчәктә дә илебез иминлеге хакына җаваплы яңа бурычларны уңышлы төстә башкарачагыгызга иманым камил. Ватаныбыз файдасына хезмәттә яңа үрләр, үзегезгә һәм якыннарыгызга нык сәламәтлек, иминлек телим!»

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышы 23 декабрь көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.

Депутатлар Дәүләт Советы бинасында 23 декабрьдә 8.00 сәгатьтән башлап теркәлә.

Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

АВЫЛ БИЗӘГЕ

Шәҗәрә

Алексеевск районының Коры Көрнәле авылында Шиһабетдиновлар гаиләсен авылыбызның бизәге дип йөртәләр. Эш-гамәлләре генә түгел, йорт-җирләре дә ерактан, тау башыннан балкып, бу сүзгә туры килеп тора аларның.

гаилә архивыннан

Зөбәрҗәт туй – еллар сынавына бирешмәгән олы мәхәббәтнең чагылышы. Йорт хуҗалары Бәдертдин ага белән Дания апа – әнә шундый бәхетле пар. Гаилә булып яшәүләренә 55 елдан артып киткән. Әле хәзер дә дөнья мәшәкатьләрен үз итеп яши алар. Оныклары Миләүшә, миңа дәрес әзерләргә дә булышалар, дип юкка гына мактанмый торгандыр инде. Бу кадәр вакыт бергә яшәү өчен сабырлык, бер-береңнең күңел халәтен тоеп, күз карашыннан аңлашып яшәү кирәклеген үз үрнәкләре белән исбатлаган алар. Тату гаиләдә өч кыз һәм бер малай дөньяга килә. Балаларга да яхшы тәрбия һәм белем биреп, туган туфракка мәхәббәт хисе тәрбиялиләр. Хәзер һәркайсы үз тормышын корып, өчесе туган авылында яши. Диләрә исемле кызлары ерак түгел Кыр Шонталысында гаилә корган.

«ВКонтакте» социаль челтәрендә «Шиһабетдиновлар гаиләсе» дип аталган шәхси бит тә бар. Аны кызлары, гомер буена укытучы булып эшләп, пенсиягә чыккач китапханәгә күчкән Дамирә ханым алып бара. Ә күп еллар мәдәният йортында эшләгән, соңгы ике елда гына авыл җирлеге башлыгы вазыйфасын үз җилкәсенә алган Дилбәр ханымга күбрәк авылдашлары турында кайгыртырга туры килә. «Көн дими, төн дими, армый-талмый туган авылына хезмәт итә», – диләр аның хакында. Туганнарыныкы гына түгел, авылның да тоткасы икән бу гаилә. Төп нигездә инде 20 ел уллары Ленар киленнәре Гөлшат белән гореф-гадәтләрне дәвам итә. Зур булмаса да, фермер хуҗалыгы оештырганнар. Бәдертдин абый белән Дания апа зирәк киңәшләре белән ярдәм итәләр. Хәер, башка эшләре дә хәттин ашкан. Аларның бүген 7 оныгы, 5 оныкчыгы бар. Нәкъ элеккеге кебек, бу йортта туганнар җыелыша, гаилә бәйрәмнәре үтә, кунаклар өзелеп тормый. Алар шулай бергә-бергә яшәргә өйрәнгәннәр.

...Бөтен районда дан тоткан киез итек басучы Мингалим абый кызы Дания Шиһабетдиновлар гаиләсенә килен булып төшкәндә, аны каената, каенана, Бәдертдин абыйның күп санлы абый-апалары каршы ала.

– Әниебез безгә бөтен яклап үрнәк ул. Әби белән 26 ел буена дус, тату, бер сүздә булып гомер итте, – ди Дилбәр ханым. – Ике якның туганнары һәрвакыт аралашып, бердәм булып яшәдек. Кирәк чакта ярдәм кулы суздык. Бергәләп ял иттек. Төп йорт булгач, гел кеше иде бездә. Әниебез бервакытта да караңгы чырай күрсәтмәде.

Бәдертдин абый хезмәт юлын 15 яшендә, совхозда төрле эшләргә йөреп башлый, аннан «корыч айгыр»ны эшкә җигә. Белемен күтәреп, кырчылык бригадиры, идарәче, агроном була. Лаеклы ялга чыккач та, фермер хуҗалыгында күп еллар агроном булып эшли. Гомуми хезмәт стажы гына да 57 ел! Ире иртә таңнан караңгы төнгә чаклы эштә булганлыктан, өйдәге мәшәкатьләр күбесенчә хатыны җилкәсенә төшә, ә ул барысына да өлгерә. Балаларына матур итеп кием дә тегеп кигертә, тәмле ризыклар белән дә сыйлый. Совхоз эшендә дә сынатмый. Оныклары аның ашханәдә эшләгәнен бигрәк тә бер җылылык белән искә төшерәләр. «Шуңа күрә әбиебез безне гел тәмле ашлар белән сыйлый да инде», – диешәләр. Пешерү-төшерү эшенә кулы ята, ашханәдә эшләп өйрәнгән, янәсе.

Авылда үткәрелгән барлык иҗтимагый, мәдәни чараларда иң актив кешеләр дә – Шиһабетдиновлар, оештыручылар да алар. 230 кеше яшәгән авылда халык театры да, фольклор ансамбле дә бар. Урам бәйрәмнәре, Өлкәннәр көне, каз өмәләре гөрләп үтә. Инде ничә еллар нәсел-нәсәпләрен өйрәнеп, ата-бабалар, туганнарын барлау белән дә шөгыльләнәләр. Шәҗәрә төзеп, истәлек булып калган ядкәрләрне, архивтагы документларны барлап, бүгенге көнгә килеп җиткән гореф-гадәтләрне киләчәк буынга җиткерүне үзләренең бурычлары дип саныйлар. Көч сынарга, җиңү яуларга дип, зона ярышы узган Яңа Чишмәгә дә 15 кеше китә алар. Бу бәйгедә катнашу өчен нәсел агачы төзү генә җитми бит әле. Һәрьяклап уңган, булган икәнлегеңне дә күрсәтергә кирәк. Монда да сынатмыйлар. Тәм-томнардан сыгылып торган өстәлләре, кул эшләре, сандык төбендә кадерләп сакланган Коръән китабы җюри әгъзаларында бик зур кызыксыну уята. Сәхнәдә дә, әниләре, әбиләреннән калган киемнәрне киеп, чын артистларча, үз гаиләләре белән горурланып чыгыш ясыйлар. Мондый гамәлләре өчен авылдашлары да рәхмәтле аларга. «Бу күркәм гаилә Алексеевск районы данын яклады. Димәк, алар районда беренчеләр, безнең өчен дә зур горурлык бу. Рәхмәт үзләренә», – ди авылдашлары Фалия Хәбибуллина. Алсу Нәҗметдинова да: «1991 елда Казаннан күчеп кайттык. Шулвакыт Дания апа әниемә мич биреп чыгарды. Ул вакытта кибеттә мондый әйберләр юк иде бит. Кинәндек инде, бик җылы булды. Рәхмәт үзләренә. Хәзер дә шул вакыйганы гел искә алып сөйлим», – дип хатирәләрне барлады.

Хатирәләр дигәннән, бүген Бәдертдин аганың әтисе Мифтахетдинне дә бик еш искә ала алар. Бигрәк тә оныклары. Аларның бабалары Беренче Бөтендөнья сугышында катнашкан. Балаларына, оныкларына ул андагы вакыйгалар турында сөйләгән. Сугыш кырында, ат җигеп, пулеметлар ташыган. Үзе бик шук, кызык-кызык әйберләр уйлап чыгарырга маһир булган. Әбиләре Асия дә, шул чорның күп хатын-кызлары кебек үк, Бөек Ватан сугышында җиңүне якынайту өчен күп көч куйган. Кырда урак урган, ашлык та эшкәрткән. Терлекчелектә дә эшләгән. Иң авыры кышның салкын көннәре һәм төннәрендә авылдан читтә, Новоспасск янында кышлауда яшәү булды дип сөйли торган була ул. Эреле-ваклы балалар белән берничә гаилә землянкада көн күрә. Терлекләрне ашатудан-эчертүдән тыш, аларны ач бүреләрдән дә сакларга кирәк була. Шулай итеп, авырлыкларны хезмәт белән җиңә белгәннәр. Озын караңгы кичләрдә сугышка җибәрү өчен оекбаш-бияләйләр бәйләгәннәр. Әйтерсең лә тарих кабатлана. Хәзер авылда бу эшне дәвам итәләр. Бүген дә хатын-кызлар, «Яшь наратлар» көен көйли-көйли, махсус хәрби операциядә хезмәт итүчеләргә оекбашлар бәйлиләр. «Авылыбыздан дүрт егетне озаттык. Җылы оекбашларыбызны үзләренә дә биреп җибәрдек. Казанга барып, хәлләрен дә белеп кайттык», – ди Дилбәр ханым.

Мобилизацияләнүчеләргә бүләкләр әзерләү эшен дә авылда Бәдертдин абый кызлары – Дилбәр Казакова белән Диләрә Гайфуллина оештырган.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Соклану

МОБИЛИЗАЦИЯЛӘНГӘН ЕГЕТНЕҢ ТУГАННАРЫ:

«Шул юлдан үзенә йөрергә язсын»

Чуашстанда яшәүче 26 яшьлек Минсәет хәрби хезмәткә чыгып китәр алдыннан башланган эш бөтен авылны берләштерә. Хәзер Татар Согытында яшәүчеләр якташларының исән-имин әйләнеп кайтуын теләп дога кыла.

Минсәеткә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакыру килгәч, авылдашлары аның күңелен күрергә тырыша. Татар Согытында егеткә ярдәм итү теләге белән акча җыярга тотыналар. Бу эшне мәктәп укытучылары башлый, аннары башкалар да кушыла. Кыскасы, шактый гына сумма җыела. Тик Минсәет андый егет түгел, акчадан баш тарта.

– Энебезнең улы ул. Кечкенәдән тырыш булды, кешеләргә ярдәм итеп үсте. Ялгыз яшәүче ике туганыбыз бар иде. Минсәет – шул әбиләрнең карын көрәп, бар эшләрен эшләп үскән бала. Һәр нәрсәне үзе булдырырга тырышты, – ди апасы Гөлнур Сабитова. – Шуңа күрә аның җыелган акчадан баш тартуы гаҗәп тә түгел. Мине 11 ел буе укыткан кешеләрдән ничек итеп акча алыйм инде, янәсе. Шаккаттык. Әмма җыелганны кире таратып булмый бит инде. Ничек итсәк иттек, акчаны Минсәеткә тапшырдык. Ул исә көтелмәгән адым ясады.

Минсәет тота да хәрби хезмәткә чыгып китәр алдыннан җыелган акчаны таш сатучы оешмага илтеп бирә. Теләге – авыл урамнарына таш җәйдертү. Аның бу гамәлен белеп алган авылдашлары дәррәү күтәрелә. «Ватсап»тагы авыл төркемнәре шау килә. Авылдашлар һәм читтә яшәүче якташлар Минсәетнең эшен дәвам итәргә алына. Тиз арада тагын 1 миллион сумнан артык акча җыела.

– Бездә өч урам бар. Ташны һәр урамга, тыкрыкка җитәрлек итеп кайтарттык. Хәтта авыл башындагы чүп ташлау мәйданына да, чишмәгә илтә торган юлга да таш түшәлде, – ди Гөлнур ханым. – Бер уйласаң, мондый гамәлнең берние дә юк сыман. Үз авылын яраткан кеше эше бу. Без аның исән-имин әйләнеп кайтуын көтәбез.

Минсәетне 19 октябрьдә мобилизацияләгәннәр. Ул Ульянда хәрби әзерлек узган. Шушы көннәрдә генә әти-әнисен, туганнарын, йөргән кызын күрергә дип, берничә сәгатькә авылына кайтып киткән. Быел өйләнәсе дә була әле ул. Әмма Ватанны сакларга чакыргач, өйләнү кичектерелә. Өмете зур: тиздән җиңеп кайтып, туйлар гөрләтергә уйлый.

– Ул армия сафларында булып кайткан иде инде. Шуңа да куркып калмады, бармау юлларын эзләмәде. Командирлары бик ярата икән үзен. Башка солдатлар белән уртак тел табып, аларны юатып, өметләндереп тора икән, – ди Гөлнур ханым. – Әти-әнисе дә, барлык туганнары да догада торабыз. Тиздән аларны махсус операциягә кертәчәкләр. Үзе салган юлларыннан үзенә йөрергә язсын иде. Изге эше белән күпме кешене артыннан ияртте. Алар һәркайсы Минсәетнең кайтуын теләп тора. Инде чит җирләрдә дә фәрештәләр саклап-яклап йөртсен!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

гаилә архивыннан

КУЛДА – КӨРӘК, КҮҢЕЛДӘ – ТЕЛӘК

Бәйгедән соң

Татарстанның Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы уздырган «Эколидер» республикакүләм бәйгесенә нәтиҗә ясадылар. Ул быел 18 нче тапкыр үткәрелде. Бәйгедә катнашырга теләк белдереп, 327 гариза килгән. Ел буе табигать сагында торучылар арасында сәнәгать оешмалары да, балалар бакчасы коллективлары да, мәктәпләр, вузлар, гап-гади кешеләр, журналистлар да бар.

Чараны ачып җибәргән Татарстан Премьер-министры урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин табигатьне саклауның әһәмиятен ассызыклады.

– Татарстан икътисадый яктан алдынгы санала. Шулай булгач, табигатькә дә зыян салына. Димәк, безгә тирә-якны ныклап саклау бурычы да куела. Безгә әйләнә-тирәне киләчәк буыннарга пычратмыйча тапшырырга кирәк. Без бу хакта яшьләргә сөйләргә тиеш, – ди Рөстәм Нигъмәтуллин.

Быелгы «Эколидер» чарасы Татарстанның Экология һәм табигать министрлыгының 30 еллык юбилее белән бергә үткәрелде. Сәхнәгә тәбрикләргә чыккан һәркем, әле сезгә 30 гына елмыни, дип гаҗәпләнүен белдерде. Министр Александр Шадриков, аз вакыт эчендә кешеләр күңелендә озак эшләгән кебек калулары өчен, тармак ветераннарына рәхмәтен җиткерде.

– Бүгенге нәтиҗәләр өчен без аларга рәхмәтле. Алар биргән күрсәтмәләр белән эшлибез, – ди министр. – «Эколидер» бәйгесе мәктәп балаларын, укытучыларны, галимнәрне, сәнәгать өлкәсендәге кешеләрне берләштерә. Ел саен иң яхшыларын сайлап алу, бүләкләү аларга киләсе елда да зур эшләр башкарырлык көч бирә. Табигать сагында булган һәркем алдында башыбызны иябез.

Экологларның эшчәнлегенә Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова да зур бәя бирде. «Сез безне бәхетле итәсез. Сезнең ярдәм белән бездә һәр почмакта матурлык хакимлек итә. Министрлыкны матурлык тудыручы һәм яхшы кәеф өләшүче оешма дияр идем», – ди Татьяна Ларионова.

Җиңүчеләр арасында Әтнә районының Югары Көек авылында гомер итүче 75 яшьлек Габдуллаҗан абый Нигъмәтҗанов та бар иде. Ул үз гомерендә 7 мең агач утырткан. Аны Татарстанда гына түгел, бөтен дөньяда беләләр икән. Испания журналистлары да Габдуллаҗан абый турында сюжет төшереп киткән. Мәскәү журналисты Валдис Пельш та Әтнәдә кунак булып киткән. Аның хакында 1 нче каналдан күрсәткәннәр дә инде.

– Берүзем 7 мең төп агач утырттым. 63 төрдә. Шуның 40ы безнең якларда үсә торган, 23 төре башка климатка ияләшкән агачлар, – ди ул. – Безнең авылда чишмә бар. Аны гомер буе әти карап торды. Хәзер ул эш миңа калды. Агачларны 1970 елдан утырта башладым.

Аның үзе генә шулкадәр үстерә алуына гаҗәпләнүчеләр дә бар икән. Эшкә күңел бирсәң, утыртырга да, тәрбияләп торырга да вакыт җитә, ди үзе.

– Кулда – көрәк, күңелдә теләк булса, агач үсә ул, – ди Габдуллаҗан абый. – Шушы эшем өчен Казанга чакырырлар дип уйламадым да. «Әтнә таңы» газетасы мөхәррире Гөлнар кыстады мине. «Әйдә әле, Габдуллаҗан абый, син дә катнаш», – диде. Аллага шөкер, җиңүче булдым.

Гөлгенә ГЫЙЛЬМАНОВА

Редакциядән. «Ватаным Татарстан» журналисты Гөлгенә Гыйльманова «Басма матбугаттагы иң яхшы язма» номинациясендә беренче урынны алды.

«Татар-информ» / Салават Камалетдинов

Бәйрәм көнне Татарстан экологларына 30 машина тапшырдылар.

Сатар түгел, алыр чак

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Яшерен-батырын түгел, кеше ипотека рәсмиләштергәндә, иң беренче чиратта, аның айлык түләвенә игътибар итә. Бүген ипотекага алынган бер бүлмәле фатир өчен айлык түләү 40 мең сумга якын. Шул ук вакытта кеше шундый ук бер бүлмәле фатирны ике тапкыр арзангарак – уртача 20 мең сумга арендалап тора ала. Мондый шартларда фатирларга сорауны ничек арттырып була соң?

– Торак базарында үзгәрешләр фатир бәяләре азмы-күпме төшкән очракта гына күзәтелергә мөмкин. Ташламалы ипотека программасы икенчел торак базарындагы фатирлар өчен дә гамәлдә булырга тиеш. Юкса бүген иске йорттан фатир алганда ипотеканы ким дигәндә 10 процент белән генә рәсмиләштерергә мөмкин, – ди Фәнис Хөсәенов.

Сатып алучы ота

Риелтор Эльвира Рәхимуллина фикеренчә, ташламалы ипотеканың 8 процентлыга әверелүенә борчылырга кирәкми. Ник дигәндә, фатир сатып алучыга төзүчеләр хәзер үзләре дә яхшы гына ташлама ясый. «Шуңа күрә ташламалы ипотека буенча процент ставкасы гамәлдә түбәнрәк булачак», – дип ышандыра ул.

Белгеч сүзләренә караганда, бүген Татарстанның икенчел торак базарындагы фатирларга сорау кимегән. Шуңа бәйле рәвештә аларның хаклары да төшкән.

– Яңа фатирларга сорау югары. Ник дигәндә, бүген яңа фатир сатып алучылар өчен отышлы программалар эшләп килә. Шул ук транш программасын гына алыйк. Аның нигезендә кеше йорт төзелеп кулланылышка тапшырылганчы һәр ай саен 1 сум гына кредит түләп тора ала. Яңа елга кадәр төзүчеләр тарафыннан бирелә торган субсидияләнгән 0,1 процентлы кредит та гамәлдә әле. Бәяләргә килгәндә, яңа йортларда төзүчеләр әллә ни зур ташламалар ясый алмый. Әмма субсидияләнгән түбән ставка хисабына алар да отышлы тәкъдимнәр ясарга тырыша, – ди Эльвира Рәхимуллина.

Белгеч фикеренчә, бүген фатир бәясеннән бигрәк, аны алырга мөмкинлек биргән кредитның процент ставкасына һәм айлык түләүгә игътибар итәргә кирәк.

– Бүген фатир сату өчен кулай вакыт түгел. Фатир сатып алу өчен исә хәзер менә дигән чор. Булган фатирын сатып, зуррагын алырга теләүчеләр дә ота. Дөрес, булганын очсызрак бәядән сатачаклар, әмма шул ук вакытта яңасын бик отышлы шартларда алып калырга өлгерәчәкләр, – ди риелтор.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләүләре өчен «Түбән Кама район үзәк күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең бүлек мөдире **Ганиева** Зөлфирә Кыяметдин кызы; «Татарстанның медицина техникасы һәм фармациясе» дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры урынбасары **Минһаҗетдинов** Илшат Габделбарый улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **Лука Крымский медале** белән бүләкләнделәр

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Кудрявцева** Алевтина Николаевна **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың финанс системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бюджет сәясәте бүлеге башлыгы **Гарифуллин** Наил Мөдәррис улы; республикада гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча шартнамәле бүлекчәләре идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы **Мотыйгуллин** Рафаил Нурхәмәт улы, Татарстан Республикасы Граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Казан шәһәре муниципаль берәмлеге буенча идарәсе башлыгы **Фазлыев** Эмиль Марс улы; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының гомуми бүлеге өлкән белгече **Гапсәләмова** Диларә Камил кызы; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Дияров Илсур Гомәр улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы **Дияров** Илсур Гомәр улы; прокуратура органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Рамазанова** Венера Котдус кызы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, ветераннар хәрәкәтен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы ветераннары (пенсионерлары)» ветераннарның җирле иҗтимагый оешмасы Советы әгъзасы **Гарипов** Шәфигулла Зәйнулла улы; гуманитар проектларны тормышка ашыруга зур шәхси өлеш кертүе һәм актив гражданлык позициясе өчен (Чаллы шәһәре) **Гатин** Рөстәм Равил улы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «ДАРКАТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Исаев** Дмитрий Владимирович, «Агромастер» ПК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Исламов** Илгиз Зәкиҗан улы, шәхси эшкуар **Котов** Геннадий Александрович, «БЕРДӘМ РОССИЯ» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлекчәсе Кайбыч җирле бүлекчәсе башкарма секретаре **Лотфуллина** Рушания Галимҗан кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча шартнамәле бүлекчәләре идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Әлмәт филиалы Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте федераль янгынга каршы көрәшү хезмәте отряды 32 янгын сүндерү-коткару часте башлыгы **Веретенников** Павел Валерьевичка, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең янгын сүндерү хезмәте башлыгы урынбасары – янгын сүндерү хезмәтенең дежур сменасы башлыгы, эчке хезмәт подполковнигы **Зәйнуллин** Илнар Харис улына, «Татарстан Республикасы Граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасы Эзләү-коткару хезмәте» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесенең 2 номерлы зона эзләү-коткару отряды (Казан) башлыгы **Ковалев** Юрий Александровичка, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең 11 янгын сүндерү-коткару отряды 87 янгын сүндерү-коткару часте башлыгы, эчке хезмәт подполковнигы **Хәйруллин** Рөстәм Таһир улына **«Татарстан Республикасының атказанган коткаручысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Беренче Төзелеш Идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорының капиталь төзелеш һәм эксплуатация буенча урынбасары **Винокуров** Владимир Валентиновичка **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Казан шәһәре Вахитов районының «СОлНЦе» махсуслаштырылган олимпиада-фәнни үзәге» урта гомуми белем бирү мәктәп-интернаты» аеруча сәләтле укучылар өчен муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Шмаков** Павел Анатольевичка **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Свидетельство серии 16 номер 127250 от 26.09.2021, выданное ООО «Учебный центр «Драйв» на имя Ахметова Наиля Равилевича, считать недействительным в связи с утерей.

Спорт

vk.com

Булды бу!

Иң яхшы финал! Дөнья чемпионатында Аргентина белән Франция арасында хәлиткеч очрашуны күпчелек әнә шулай бәяли. Французларның 24 яшьлек йолдызы Килиан Мбаппе берүзе 3 туп кертте. Тик бу гына аз булып чыкты. Көньяк Америка уенчылары Аргентинаның – дөньядагы иң шәп команда, Лионель Мессиның исә иң шәп футболчы булуын раслады. Тарихка да шулай язылачак.

Моннан 4 ел элек Россиядә узган дөнья чемпионатының 6 очрашуын Казан кабул итте. «Казан Арена»га җыелган тамашачы Бразилия, Бельгия, Германия, Испания командаларының уенын карап кинәнде. Ул елны чемпион исемен яулаган французлар исә Казанда ике очрашу уздырды. Шуның берсе – Аргентинага каршы. Финалның 1/8 өлешендә узган әлеге матчны чемпионаттагы иң шәп уеннарның берсе дип атадылар. Франция, 4:3 исәбе белән отып, кубокка таба беренче зур адымын ясады. Аргентина исә турнирдан төшеп калды. 2014 елда Бразилиядә узган чемпионатта көмеш медаль откан Лионель Мессига алтын инде эләкмәс дип фаразлаучылар да булды. Шулай итеп, Катардагы чемпионат аның өчен соңгы мөмкинлеккә әверелде.

Якшәмбе кичендә Аргентина белән Франция арасындагы очрашуны күргән спорт сөючеләр футбол тарихында зур сәхифә язылуга шаһит булды. Командалар җанатарларга маҗаралы футбол бүләк итте. Уен кырына чыккан исемнәрне чагыштырсак, французлар өстенрәк саналды. Ләкин алар аңга килгән арада Аргентина беренче таймда ике туп кертеп куйды. Җитәме шул? Юк икән! Икенче таймда 24 яшьлек Мбаппега исәпне тигезләр өчен нибары 90 секунд кирәк булды. Ике тайм гына җитмәде. Өстәмә вакытта Месси тагын бер туп кертте, әмма каршы якта Мбаппе бар! Финал очрашуларында 1966 елдан бирле өч туп кертүче булмаган. Нәтиҗәдә җиңүчене пенальти ярдәмендә ачыкларга туры килде. Монысында Көньяк Америка яхшырак булып чыкты. Месси – иң яхшы уенчы, Аргентина – иң шәп команда! Дөнья чемпионатын Согуд Гарәбстанына оттырудан башлаган команда бу!

Аргентина соңгы тапкыр 1986 елда дөнья чемпионы булган иде. Ул вакытта иң шәп уенчылары – Диего Марадона. Тагын бер елдан Лионель Месси дөньяга килә. Аны һәрвакыт Марадона белән чагыштыралар. 2022 елның 18 декабрендә ул аның белән бер дәрәҗәдә булганын раслады. Аңа кадәр исә гәүдә үсешенә бәйле катлаулы авырудан дәваланырга, салфеткага язып, беренче килешү төзергә, күп сынаулар аша узарга, җиңәргә генә түгел, җиңелергә дә өйрәнергә кирәк иде әле. Инде хәзер ни булыр? Юк, китәргә җыенмый әле. Аның әле уйныйсы, җанатарларын сөендерәсе килә.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

ДӨНЬЯ ЧЕМПОНАТЫНДАГЫ ИҢ КЫЙММӘТЛЕ КОМАНДАЛАР

Transfermarkt порталы уенчыларның бәяләрен берләштереп, дөнья чемпионатындагы иң кыйммәтле командаларны ачыклаган (бәяләр – евроларда)

1. Англия – 1,26 млрд	6. Испания – 877 млн
2. Бразилия – 1,14 млрд	7. Аргентина – 645 млн
3. Франция – 1,03 млрд	8. Голландия – 587 млн
4. Португалия – 937 млн	9. Бельгия – 563 млн
5. Германия – 886 млн	10. Уругвай – 450 млн

АРГЕНТИНА ҖЫЕЛМА КОМАНДАСЫНЫҢ ИҢ КЫЙММӘТЛЕ УЕНЧЫЛАРЫ

Лаутаро Мартинес, 25 яшь («Интер»), 75 млн
Кристиан Ромеро, 24 яшь («Тоттенхэм»), 55 млн
Лионель Месси, 35 яшь («ПСЖ»), 50 млн
Лисандро Мартинес, 24 яшь («Манчестер Юнайтед»), 50 млн
Анхель Корреа, 27 яшь («Атлетико»), 40 млн

ФРАНЦИЯ ҖЫЕЛМА КОМАНДАСЫНЫҢ ИҢ КЫЙММӘТЛЕ УЕНЧЫЛАРЫ

Килиан Мбаппе, 23 яшь («ПСЖ»), 160 млн
Орельен Тчуамени, 22 яшь («Реал»), 80 млн
Кингсли Коман, 26 яшь («Бавария»), 60 млн
Усман Дембеле, 25 яшь («Барселона»), 60 млн
Жюль Кунде, 24 яшь («Барселона»), 60 млн

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

МАТУР КЕШЕ

Хушлашу

Ихлас һәм тыйнак. Виртуоз һәм кабатланмас. Игътибарлы һәм ярдәмчел. Һәр нәрсәдән миллилек эзләүче. Татарстанның халык артисты, баянчы Рамил Курамшинны соңгы юлга озатырга килгән халык аны шундый сүзләр белән искә алды. Аңа 75 яшь туласы иде. Тагын бер мәшһүребез түгәрәк юбилеен күрмичә бакыйлыкка күчте.

Рамил Курамшинның үлеме турында хәбәр күпләрне тетрәндергәндер. Аны мескен хәлдә, кызгануга лаек кеше иде дип, үз файдасына борып күрсәтүчеләр, тасвирлаучылар да булмады түгел. Үз шәхесеңне үз телең белән үк кимсетү түгелме соң инде бу? Бу күренеш белән күңел килешми һәм килешмәс тә, әлбәттә... Шуңа күрә киткәннәр турында матур, якты сүзләр генә языйк әле. Гайбәт болай да күп заманда яшибез ләбаса. Ә Рамил абый турында матур хатирәләр күп. Үзе шундый булгангадыр инде. Асыл мәгънәсендә матур кеше иде ул чөнки.

Барыбызның да кимчелегедер инде ул – шәхес киткәч кенә, аны телгә алуларыбыз ешая, үкенеч катыш кызгану белән, әйтәсе җөмләләребезгә «иде» сүзен өстәргә туры килә. Рамил Курамшинны озату мәрасименә җыелгач та, аның белән хушлашырга килүчеләрдән иң элек шул хакта сораштык.

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең һәм Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбленең сәнгать җитәкчесе Айдар Фәйзрахманов әйтүенчә, Рамил Курамшин ахыргы көннәренә кадәр игътибардан өзелмәгән. Филармония вәкилләре дә, иҗатташ дус-ишләре дә аның хәлен белешеп торган. Үзе дә берәр ай элек аның белән сөйләшкән булган.

– «Шәхес кадерен үлгәч кенә беләбез», – дию Рамил абыйга туры килми. Кадере булмаган баянчы Илһам Шакировка уйный алмый ул! Кадер сәнгатькә карап бәяләнә, – диде Айдар Фәйзрахманов. – Рамил абый безнең өчен, җырчылар өчен маяк булды. Рамил Курамшин уйнаган җырчы халык бәясен алган җырчы санала иде. Кемгәдер сәнгатьнең югары дәрәҗәсенә җитәргә кирәк икән, ул, әлбәттә, Рамил Курамшин белән эшләргә тиеш иде. Аккомпаниатор булудан тыш, шәхес буларак та үрнәк ул. Тәртип, зәвык, үз-үзен тоту дисеңме... Инструменталь әсәрләре исә классик әсәрләр белән беррәттән өйрәтелә. Рамил абыйга филармониядән дә игътибар булды. Матди, рухи ярдәм күрсәтелде. Хәлен белешеп тордык. Соңгы көненә чаклы радиодан аның әсәрләре яңгырады. Сәнгать кешесе өчен бу да мөһим бит. Рамил абыйга шәхсән мин дә бик рәхмәтле. Ул миңа игътибарлы иде. Аның уйнавына карап, мин дә, кызыгып, җырчыларга баянда уйный башладым. Рамил абый матур яшәде. Сәнгатьтә дә, кешеләр белән дә, гаиләдә дә матур иде. Аның белән очрашып сөйләшү дә үзе бер гомергә тиң иде бит.

Филармония хезмәткәрләре Рамил абыйларда үләренә берничә көн элек кенә кунакта булган. «Без барган көнне салмак кына сөйләште, әллә ни ашамады да. Хәтере яхшы иде аның. Янәшәсендә генә радиосы булыр иде. Ансамбль концертларын яратты ул. 70 яшьлек юбилее бик матур узды. Шәм кебек басып торды ул сәхнәдә. Инсульт бәреп екмаса...» – диеште алар.

Ваһапов фонды җитәкчесе Рифат Фәттахов та Рамил Курамшинны, беркайчан да мескен булмады, дип искә алды.

– Матбугатта аны шундый итеп күрсәтү күренеше бар. Моның белән килешмим. Ул лаеклы тормыш юлын үтте, горур, киңкырлы шәхес булды. Иң элек – музыкант һәм баянчы. Татарның бөек баянчысы! Ул үзеннән соң гаҗәеп дәрәҗәдә бай мирас калдырды. Рамил Курамшин – сәнгатьтә новатор булган кеше дә, – диде ул. – Аңа игътибар булды. Ул риза булып китте.

Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев исә Рамил Курамшинны милләт өчен борчылучылардан иде дип искә алды.

– Рамил туганыбызны озатырга шулкадәр халыкның җыелуы да аның ни дәрәҗәдә затлы, зыялы шәхес булуын дәлилли. Музыка, тарих, милләт – һәр нәрсәгә җанын биреп борчылып сөйләр иде. Ул милләтпәрвәр булды. Һәр җирдән миллилек эзләде. Баянында, моңнарында, сөйләшүдә, җырларында... Илһам ага: «Начар кешедән яхшы сәнгать әһеле чыкмый», – ди иде. Рамил кеше буларак та, сәнгать әһеле буларак та искиткеч булды, – диде ул. – Олуг шәхесләребезне бәяли белергә кирәк. Рамил туганыбыз турында истәлекләр китабы чыгарга, аның исемендәге мәдәният, сәнгать йортлары да, урамнар да булырга тиеш. Шулай итеп кенә милләтебез шәхесләрен кадерли алабыз. Озатканда матур сүзләр күп сөйлибез. Әмма хәтеребез бик кыска. Тиз онытабыз. Рамил әфәндене онытмасак иде.

Татарстанның халык артисты Гөлзада Сафиуллина иҗатташ дусты турында менә нәрсә ди:

– Ул иң ихлас, тәрбияле кеше һәм күп баянчыларны тәрбияләгән бөек музыкант булып калачак. Аның белән нинди генә сәхнәләрдә чыгыш ясамадык. Ул булганда, сәхнәгә курыкмыйча чыга идем. Рамил бер нотага да ялгышмас иде. Репетиция ясамыйча сәхнәгә чыкмады. Пөхтә, чиста булды. Аннан үрнәк алалар иде. Аны тәрбияләгән туган ягына, ата-анасына зур хөрмәт һәм рәхмәт. Дустыбыз тыныч йокласын. Бөтен эшен башкарып китте. Китаплары калды, җырлары, мәктәбе калды.

Рамил Курамшинның тормыш иптәше Рузалия ханымның бу көнне күзләре яшьле, күңеле тулган иде, дип кенә әйтү аз. Алар 40 елга якын бергә булганнар.

– Минем өчен ул дөнья йөзендәге иң әйбәт кеше иде. Кешеләргә һәрвакыт ярдәм итте. Хәленнән, мөмкинлегеннән килгәнчә булыша торган бәндәләрдән иде, – дип сөйләде ул, хисләрен тыя алмыйча. – Рамил мактанып, шапырынып йөрмәде. Бик тыйнак булды. Тәртипле иде. Мин рәхәттә яшәдем.

P.S. Рамил Курамшинны Түбән Новгород өлкәсенең Сергач районындагы Кучкай-Пожары авылында җирләделәр. Аның васыяте шундый иде.

Рамил КУРАМШИНның «ВТ»да басылган фикере:

> Мин Казанга килгән елларда халкыбыз арасында «Поэзиядә – Тукай, музыкада – Сәйдәш, җыр-моңда – Илһам» дигән гыйбарә йөри иде. Аннары «Илһам кебек җырчы гасырга бер генә туа» дигәне дә чыкты һәм бүгенгә кадәр яши. Әмма соңгы 20–30 елда җыр сәнгатендәге хәлләргә карап: «Юк инде, җәмәгать, бүтән Илһам Шакировлар тумаячак», – дип әйтәсе килә. Чөнки миллилеге «ташка үлчим» генә булган җырлар... һәм такмаклар гына тыңлап үскән яшь буыннан шундый ук такмакчылар гына чыгарга мөмкин.

ҺӘРКЕМНЕҢ – ҮЗ ҖЫРЫ

«ТАТАР ҖЫРЫ – 2022» НӘРСӘЛӘР БЕЛӘН ИСТӘ КАЛДЫ?

«Күңел кошы» белән хушлашу, 4 елдан соң әйләнеп кайткан Фирдүс, ретро-җырлар. Быелгы «Татар җыры» шулар белән истә калгандыр, мөгаен. Татар эстрадасы җырчыларын берләштерүче фестиваль быел да «Казан Экспо»да Ильһам Шакиров исемендәге концертлар залында узды. 3 сәгатьтән артык барган тамашаны «ВТ» хәбәрчесе карап кайтты.

Матбугат очрашуында быелгы тамашаның башкалардан бик аерылып торачагын вәгъдә иткәннәр иде. Тик үзгәрешләр әллә ни күренмәде. Әйе, яңалыклар бар. Әйтик, быелгы концерт «Ана теле», «Туган туфрак», «Мәхәббәт» һәм «Моң» бүлекләреннән торды. Тик ул бүлекләргә җырчылар һәм җырлар ни дәрәҗәдә туры килерлек итеп сайланган, гомумән кирәк идеме бу бүленеш – монысы икенче мәсьәлә.

Концертны, гадәттәгечә, Гөлназ Сәфәрова белән Искәндәр Хәйруллин алып барды. Кызу темпта, күңелле алып бардылар. Урынсыз шаяртулар да булмады үзе, тик Данир Сабировны төрек сериалларындагы артистларга охшату, Ришат Төхвәтуллинны өйләндерү мәсьәләсе, Айдар Галимовның яшьлек элексиры эчүе һәм хатын-кызның картаймавыннан тыш бераз яңарак һәм кызыгракларын да ишетәсе килде. Телгә багышланган бүлек барышында татар телендәге авыр сүзләрне аңлату, яшьләр телендә «сленг»лар белән сөйләшү кебек күренешләр булды.

Тамаша «Туган туфрак» дигән бүлектән башланып китте. Иң беренче булып сәхнәгә Татарстанның халык язучысы, автор-башкаручы Зөлфәт Хәким чыкты. Беренче чыгыш ясаганга, аңа «Алтын барс» сынын «Барс-Медиа» компаниясенең директорлар советы рәисе Камил Гәрәев тапшырды.

– Телебез, тарихыбыз саклансын, сәнгатебез булсын, дигән уйлар белән әлеге фестивальне башлап җибәргән идек. Һәм инде менә 23 ел бу юнәлештә эшлибез. Зөлфәт Хәким – татар милләтенең тугрылыклы улы, тере легенда, – диде Камил Гәрәев.

Башка артистларга «Алтын барс» сыны сәхнәдә тапшырылмады. Номинацияләрне дә инде узган ел бетергәннәр иде. Монысы сөендерә. Оештыручылар үзләренең дә, тамашачының да вакытын кайгырткан.

Халык ярты сәгать буе залга керү һәм үз урынын эзләү белән мәшгуль булдымы, әллә инде җырчыларга бәйлеме – концерт башында зал сүлпәнрәк иде, алкышларга саран булды. Халык көткән җырчылар, гадәттә, концертның икенче өлешендә була бит. Айдар Галимов, Салават, Зөфәр Хәйретдинов, Эльмира Кәлимуллина, Ришат Төхвәтуллин, Рифат Зарипов, Иркә, Филүс Каһировны башкаларга караганда җылырак кабул иттеләр. Хит җырларын башкарганда, аларга кушылып җырладылар һәм көчле алкышларга күмделәр.

«Татар-информ»/ Абдул Фархан

Концертта күптән түгел арабыздан китеп барган җырчы Эльмира Сөләймановны искә алып, аның «Балан ачы шул, балам» җырына клипларыннан өзекләр күрсәттеләр. Моңлы җырчының тавышы ишетелүгә, күпләрнең тәне чемердәп куйгандыр.

«Татар эстрадасының күңел кошы – Эльмира Сөләйманова, хуш. Бүген аны искә төшерүебез җырчыга дога булып ирешсен, аның рухын шатландырсын иде. Кеше китә – җыры кала. Аның җырлары һәрвакыт безнең белән булачак», – диде алып баручылар.

Фестивальнең бер кызыклы яңалыгы – ретро-җырлардан торган попурри. Популяр хитларыннан өзекләрне Сәгыйть Гыйбашев, Дамирә Сәетова, Гайфулла Авзалов, Радик Динәхмәтов башкарды. Тик бик кыска булды ул, җитеп бетмәде. Тамашачы да дәртләнеп киткән генә иде. Халык элек яңгыраган җырларга сусаган булган.

«Татар җыры» сәхнәсендә халык әле белеп бетермәгән яшь җырчылар да бар иде. Әйтик, иң яшь дуэт – Җәмилә Әсәдуллина һәм Илгиз Шәйхразиев. Алар быел беренче премиягә лаек булды. Тагын бер яшь башкаручы – Таңсылу әнисе Ләйсән Гыймаева белән «Әйләнеп кайтыгыз» җырын башкарды. Сүз уңаеннан, бу кичтә Ләйсән Гыймаевага «Татарстанның атказанган артисты» исеме бирелү турында да игълан ителде. Җырчы түгел, ә бәлки күбрәк Тямаевның хатыны буларак билгеле Резедә Әхмәтвәлиева да беренче «барс»ын алды.

Янәдән бүлекләргә әйләнеп кайтыйк әле. «Моң» бүлегенә Салават Фәтхетдинов, Филүс Каһиров, Ришат Төхвәтуллин һәм... Фирдүс Тямаевны куйганнар. Беренче өч җырчының ни өчен бу бүлектә булганы аңлашылса, Тямаевны чыгарырлык башка бүлек тапмаганнар дип уйлыйсы гына кала. Үзенә генә аерым берне дә багышлый алалар иде, чөнки концертта өч җыр башкаручы бердәнбер артист иде ул. «Яңа йолдыз-3» проекты җиңүчесе Фәридә Ибраһимова да тамашачыга җырын бүләк итте. Тик аның «Кермә төшләремә» дигән җыры «Ана теле һәм көй» бүлегендә түгел, «Мәхәббәт»тә булырга тиешлеге көн кебек ачык. Гомумән, бүленеш күп сораулар тудырды. Барысын да санап тормыйм.

Күп кызларның башын әйләндергән Марат Яруллин да «Татар җыры» премиясенә лаек булды. «Бик уңышлы ел килеп чыкты. Елдан артык Казанда яшим. Беренче гастрольләрем дә булды», – ди җырчы. Чыннан да, тиз күтәрелде ул. Быел гына җитмештән артык концерт биргән. Сүз уңаеннан, соңгы арада Маратка концертларында еш кына каз бүләк итәләр икән.

– Ник бүләк итәләрдер – белмим, үзенә күрә бер традициягә әйләнде инде. Беренче казны бирделәр дә, шуннан китте. Әле шунысы кызык: яшьләр – уенчык, ә олы апалар ысланган, каклаган каз бирә. Тиздән каз фермасы ачмый булмас, – дип шаяртты ул.

Ярый, Яруллин беренче «барс»ын алды һәм шуңа сөенә. Ә тәҗрибәлерәк җырчыларга бу сын нәрсә бирә? Әлеге сорауны Ришат Төхвәтуллинга бирдек. «Барс»лар җыелып, уңып баралар инде, алтыны да бетеп бара, дип шаяртты җырчы.

– Бу аның кадәр мөһим дә түгел инде. Бернинди премия, бүләк тә кирәкми. Артист кеше өчен иң мөһиме – тамашачы булу. Алар минем өчен тавыш бирмәсә, җырларымны тыңламаса, мин бүген монда басып тормас идем. «Алтын барс» – минем һәм тамашачыларымның җиңүе. Шуның белән ул кадерле һәм истәлекле, – диде Ришат.

Тамашачыга килгәндә, беренче бүлектән соң кайтып китүчеләр дә шактый булды. Концерт беткәннән соң: «Мондыйны күргән юк иде әле. Җырчылар «скучный», ярый әле Салават белән Фирдүс бар», – дигән фикерләр ишетелде. Тамашачы Зәйнәб Фәрхетдинова, Гүзәл Уразова, Илсөя Бәдретдинова кебек артистларны да күрергә теләгән.

«Татар җыры» сәхнәсендә 4 ел күренми торган Фирдүс Тямаев, ел саен катнашсаң, тәме бетә кебек, ди.

– Сагынып килдем, беренче «Алтын барс» премиясен алган кебек дулкынланам. Бүген шаккатырырга түгел, тамашачының кәефен күтәрергә, энергияле, дәртле җыр белән көч бирергә килдем, – дигән иде ул журналистларга, концерт башланганчы.

Һәм шулай булды да. Танылган җырчы иң соңгы булып чыгыш ясады һәм, гадәттәгечә, сәхнәгә чыгуга, көчле энергетикасы белән бөтен залны тутырды. Тамашачылар, урыннарыннан сикереп торып, бии үк башлады. Шул дәртле нотада концерт та бетте. Тик «Татар җыры» дигән зур исемле фестивальнең шундый җыр белән тәмамлануы гына бик күп сораулар калдырды...

Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6692 данә
Гомуми тираж – 15344 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 388

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+